**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2183**
**13.05.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 13 мартындагы 122/пр номерлы Приказы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләргә торак урын сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2020 елның икенче кварталына 53 024 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов